КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 31 декабрь г.Казань № б-200

Татарстан Республикасында массакүләм физкультура-савыктыру хәрәкәтен популярлаштыру, халыкны актив ял итүгә, физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү максатларында:

1. Татарстан Республикасында 2023 елның 11 февралендә, «Лыжня России» XLI ачык Бөтенроссия массакүләм чаңгы узышы турындагы нигезләмәгә таянып, «Лыжня России» XLI ачык Бөтенроссия массакүләм чаңгы узышын һәм «Лыжня Татарстана – 2023» республика массакүләм ярышларын үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына:

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белән берлектә, 2023 елның 11 февралендә Казан шәһәрендә, ярышларда катнашу өчен төрле яшьтәге халык катламнарын киң җәлеп итеп, «Лыжня России» XLI ачык Бөтенроссия массакүләм чаңгы узышын әзерләү һәм үткәрү эшен оештырырга;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары белән берлектә, ярышларда катнашу өчен төрле яшьтәге халык катламнарын киң җәлеп итеп, «Лыжня Татарстана – 2023» республика массакүләм ярышларын үткәрүне оештырырга.

3. Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, төрле милек формаларындагы предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә әлеге ярышларда үз хезмәткәрләренең катнашуын оештыруны тәкъдим итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына әлеге ярышларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

5. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына әлеге чаралар үткәрелә торган урыннарда хокук тәртибен саклауны һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә әлеге ярышлар үткәрелә торган урыннарда санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү максатларында тиешле чаралар үткәрүне тәэмин итүне.

6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин